**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 6 июнендәге 2353 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 12 декабрендәге 4315 номерлы «Мәгълүмат тактасын урнаштыру, элмә такта урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль закон нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»гы карарын исәпкә алып, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары эшчәнлегенең ачыклыгын, муниципаль хезмәтләрдән һәркем файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 12 декабрендәге 4315 номерлы карары белән расланган мәгълүмат тактасын урнаштыру, элмә такта урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.4.4 пунктта өченче, дүртенче, бишенче абзацларны яңа редакциядә бирергә:

«- Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты әзерли.

Хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә билгеләнгән тәртиптә килештерүгә җибәрелә.

Хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын килештерү Регламентның 3.5.3 пунктында каралган тәртиптә башкарыла»;

1.2. 3.4.4 пунктның җиденче абзацын яңа редакциядә бирергә:

«Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре: муниципаль

хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр), яки ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазифаи затка җибәрелгән баш тарту турында хәбәрнамә, яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**